| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КРКАЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КЕРКӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 2024 елның 4 октября | № 24 |

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «Федераль законның 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 30.05.2017 № 8, 17.11.2017 № 27, 29.01.2018 № 2, 19.09.2018 № 23, 14.12.2018 № 37, 22.01.2019 № 1, 20.03.2019 № 6, 02.10.2019 № 24, 12.02.2020 № 1, 17.06.2020 № 8, 13.08.2020 № 13, 12.11.2020 № 13, 26.03.2021 № 2, 10.08.2021 № 20, 28.04.2023 № 16, 01.08.2023 № 28, 19.10.2023 № 35, 18.12.2023 № 44, 25.04.2024 № 8 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәреш кертергә:

10 нчы бүлекнең 10.1.3 нче пунктының 5 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) белем һәм квалификация турында документ».

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле авылы, Советская ур., 93 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында б(http://leninogorsk.tatarstan.ru), «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Л.И.Бигманов